| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ФЕДОРОВСКИЙ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь 2022 ел. Федоровский авылы № 1

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең Федоровский торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә **карар бирәм**:

1. Тутаев урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Федоровский мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2022 елның 21 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Тутаев урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Федоровский мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2022 елның 23 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Тутаев урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Федоровский мәдәният йорты бинасы каршында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2022 елның 24 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Тутаев урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Федоровский мәдәният йорты бинасы каршында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының дүртенче этабын 2022 елның 27 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Тутаев урамы, 41 нче йорт адресы буенча урнашкан Федоровский мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының бишенче этабын 2022 елның 30 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка билгеләргә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Федоровский авыл җирлеге Федоровский торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаиләләренең балигъ булган

әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- җәйге чорда территорияне чабу
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү
- Федоровский җирлек торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту

« РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Федоровский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Кайбыч муниципаль районы Федоровский авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә Федоровский авыл җирлеге территориясендә яңа короновирус йогышы (COVID - 19) белән авыру очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемиологик чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

9. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Федоровский авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Ф.Зайнуллин**